Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

“09” ноябрь 2020 ел № 20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2018нче елның 26нчы апрелендә кабул ителгән 14нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2018нче елның 26нчы апрелендә кабул ителгән 14нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарына 2020 елның 1 октябреннән, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Саба шәһәр җирлеге Советының
2020 елның 9 ноябрендә кабул ителгән
11нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгының, аның урынбасарының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Шәһәр җирлеге башлыгы | 18 748 |
| Шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары | 13 968 |
| Депутатлар | 11 498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11 498 |